# ХАЛЫК ҖЫЕНЫ КАРАРЫ
## Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Суыксу авыл җирлегенең Чәмәк авылында халык җыены нәтиҗәләре турында

2 декабрь 2024 ел № 12

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә 2024 елның 30 ноябрьдә 10 сәгать 00 минутта узган гражданнар җыены нәтиҗәләре белән гражданнар җыены беркетмәсе төзелде «2025 елда балигъ булган һәр кешедән 1500 (бер мең биш йөз) сум күләмендә үзара салымны кертүгә ризамы Сез? " дигән сорау буенча, Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының Суыксу авыл җирлегенең Чәмәк авылында яшәү урыны буенча теркәлгән һәм торак пункт территориясендә даими яшәүче һәм алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтеп түбәндәге эшләрне башкару буенча:

а) торак пункт чикләрендә җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, тоту;

б) торак пунктның башка территорияләрен төзекләндерү

«ӘЙЕ» «КАРШЫ»

Халык җыены нәтиҗәләре турында беркетмә нигезендә:

Гражданнар җыенында сайлау хокукына ия булган катнашучылар исемлегенә 14 (ундүрт) катнашучы кертелгән, 8 кеше тавыш бирүдә катнашкан, бу 57,1% тәшкил итә

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча, гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә билгеләнде:

халык җыенында 8 (сигез) катнашучы «ӘЙЕ» позициясе өчен тавыш бирде;

«КАРШЫ» позициясе өчен җыенда катнашучы 0 (ноль) тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә, халык җыены карар итте:

1. Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Суксу авыл җирлегенең Чәмәк авылында халык җыены булып узды, Халык җыенының нәтиҗәләре гамәлдә дип танырга.

2. 2025 елда үзара салым акчасын Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Суыксу авыл җирлегенең Чәмәк авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәм даими яшәүче балигъ булган һәр кешедән 1500 (бер мең биш йөз) сум күләмендә кертергә.

3. Алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәге эшләрне башкару өчен җибәрергә:

а) торак пункт чикләрендә җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, тоту;

б) торак пунктның башка территорияләрен төзекләндерү.

4. Агымдагы карарны мәгълүмат стендларында, Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының авыл җирлекләре бүлегендәге рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында тарату юлы белән халыкка җиткерергә http://pravo.tatarstan.ru/.

5. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына кертү өчен җибәрергә

Халык җыенында рәислек итүче Р.С.Низамиев

Гранданнар җыенының 30.11.2024 №10 карарына кушымта

Кондырлы авылы мобилизацияләнгән гражданнары
һәм аларның гаилә әгъзалары исемлеге

| № | ФИО | Год рождения | Адрес |
|---|---|---|---|
| 1 | Жбанов Дамир Николавеич | 1994 | Кондырлы авылы, ул. Х.Такташ ур., 2 йорт |
| 2 | Жбанова Алсу Илдаровна | 1972 | Кондырлы авылы, ул. Х.Такташ ур., 2 йорт |
| 3 | Ахмадеев Ильназ Илдарович | 1990 | Кондырлы авылы, ул. Х.Такташ ур., 2 йорт |